# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О нематериальном культурном наследии в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 марта 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 26 мая 2017 года № 34-ЗРТ «О нематериальном культурном наследии в Республике Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 41 (часть I) изменения, изложив его в следующей редакции:

«ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О регулировании отдельных вопросов в области нематериального этнокультурного достояния**

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон регулирует отдельные вопросы в области выявления, изучения, использования, актуализации, сохранения, популяризации и государственной охраны объектов нематериального этнокультурного достояния Российской Федерации в Республике Татарстан (далее – нематериальное этнокультурное достояние).

**Статья 2. Правовое регулирование отношений в области нематериального этнокультурного достояния**

1. Правовое регулирование отношений в области нематериального этнокультурного достояния основывается на положениях Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан и осуществляется Федеральным законом от 20 октября 2022 года № 402-ФЗ «О нематериальном этнокультурном достоянии Российской Федерации» (далее – Федеральный закон), другими федеральными законами, нормативными правовыми актами Президента Российской Федерации, нормативными правовыми актами Правительства Российской Федерации, настоящим Законом, другими законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

2. Понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, в каком они определены в Федеральном законе.

**Статья 3. Объекты нематериального этнокультурного достояния**

К объектам нематериального этнокультурного достояния относятся:

1) устное творчество, устные традиции и формы их выражения на русском языке, татарском языке, языках и диалектах народов Российской Федерации;

2) формы традиционного исполнительского искусства (словесного, вокального, инструментального, хореографического);

3) традиции, выраженные в обрядах, празднествах, обычаях, игрищах и других формах народной культуры;

4) знания, выраженные в объективной форме, технологии, навыки и формы их представления, связанные с укладами жизни и традиционными ремеслами, реализующиеся в исторически сложившихся сюжетах и образах и стилистике их воплощения, существующих на определенной территории;

5) иные объекты нематериального этнокультурного достояния.

**Статья 4. Категории объектов нематериального этнокультурного достояния**

Объекты нематериального этнокультурного достояния подразделяются на следующие категории:

1) объекты нематериального этнокультурного достояния федерального значения, представляющие особую историческую, культурную и научную ценность для истории и культуры Российской Федерации;

2) объекты нематериального этнокультурного достояния регионального значения, представляющие историческую, культурную и научную ценность для истории и культуры Республики Татарстан;

3) объекты нематериального этнокультурного достояния местного (муниципального) значения, представляющие историческую, культурную и научную ценность для истории и культуры муниципальных образований.

Статья 5. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в области нематериального этнокультурного достояния**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в области нематериального этнокультурного достояния относятся:

1) законодательное регулирование отношений в области нематериального этнокультурного достояния;

2) осуществление контроля за исполнением законов Республики Татарстан в области нематериального этнокультурного достояния;

3) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в области нематериального этнокультурного достояния относятся:

1) участие в осуществлении единой государственной политики в сфере культуры в части нематериального этнокультурного достояния;

2) издание нормативных правовых актов в области нематериального этнокультурного достояния;

3) утверждение государственных программ Республики Татарстан, содержащих мероприятия в области нематериального этнокультурного достояния;

4) осуществление поддержки региональных и местных национально-культурных автономий;

5) поддержка организаций народных художественных промыслов (за исключением организаций народных художественных промыслов, перечень которых утверждается уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти);

6) осуществление мер, направленных на поддержку, сохранение, развитие и изучение культуры народов Российской Федерации, проживающих на территории Республики Татарстан, сохранение этнокультурного многообразия народов Российской Федерации, проживающих на территории Республики Татарстан, в том числе нематериального этнокультурного достояния;

7) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан.

3. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области нематериального этнокультурного достояния (далее – уполномоченный орган), относятся:

1) принятие мер по выявлению, изучению, использованию, актуализации, сохранению, популяризации объектов нематериального этнокультурного достояния;

2) организация и поддержка учреждений культуры и искусства (за исключением федеральных государственных учреждений культуры и искусства, перечень которых утверждается уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти) в части выявления, изучения,

использования, актуализации, сохранения, популяризации объектов нематериального этнокультурного достояния;

3) утверждение положения о Реестре объектов нематериального этнокультурного достояния Республики Татарстан (далее – Реестр), которое содержит в том числе порядок формирования и ведения Реестра, порядок использования Реестра, порядок принятия решения о включении объектов нематериального этнокультурного достояния в Реестр и порядок исключения объектов нематериального этнокультурного достояния из Реестра, порядок присвоения объекту нематериального этнокультурного достояния категории регионального или местного (муниципального) значения;

4) принятие заявок о включении объекта нематериального этнокультурного достояния в Реестр или федеральный государственный реестр объектов нематериального этнокультурного достояния Российской Федерации;

5) внесение предложения о включении объекта нематериального этнокультурного достояния в федеральный государственный реестр объектов нематериального этнокультурного достояния Российской Федерации в установленном Федеральным законом порядке;

6) осуществление государственной охраны объектов нематериального этнокультурного достояния;

7) организация и осуществление, в том числе научными организациями Республики Татарстан, региональных научно-технических и инновационных программ и проектов в области нематериального этнокультурного достояния;

8) организация проведения экспертиз научных и научно-технических программ и проектов в области нематериального этнокультурного достояния, финансируемых за счет средств бюджета Республики Татарстан;

9) разработка государственных программ Республики Татарстан, содержащих мероприятия в области нематериального этнокультурного достояния;

10) образование экспертного совета, утверждение положения об экспертном совете и состава экспертного совета;

11) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан.

Статья 6. **Полномочия органов местного самоуправления в области нематериального этнокультурного достояния**

Органы местного самоуправления осуществляют полномочия в области нематериального этнокультурного достояния в соответствии с Федеральным законом.

Статья 7. **Реестр**

1. В Республике Татарстан в целях учета, сохранения, изучения, актуализации и популяризации объектов нематериального этнокультурного достояния регионального и местного (муниципального) значения создается и ведется Реестр.

2. Реестр является основным источником информации об объектах нематериального этнокультурного достояния регионального и местного (муниципального) значения, способах (формах) их выражения, а также местах хранения связанных с ними материальных предметов.

3. Сведения, содержащиеся в Реестре, являются открытыми, общедоступными и подлежат размещению на официальном сайте уполномоченного органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

4. Оператором Реестра является уполномоченный орган. На основании решения уполномоченного органа полномочия по эксплуатации и развитию Реестра могут быть переданы подведомственному ему учреждению.

5. Заявка о включении объекта нематериального этнокультурного достояния в Реестр может быть подана лицом, заинтересованным в охране и популяризации объекта нематериального этнокультурного достояния, или органом публичной власти в уполномоченный орган. Решение о включении объекта нематериального этнокультурного достояния в Реестр либо об отказе во включении объекта нематериального этнокультурного достояния в Реестр принимается в срок не более одного года со дня регистрации заявки в уполномоченном органе.

6. Объект нематериального этнокультурного достояния включается в Реестр решением уполномоченного органа на основании заключения экспертного совета о соответствии указанного объекта всем критериям, установленным частью 1 статьи 8 настоящего Закона, и присвоении ему категории регионального или местного (муниципального) значения.

7. Основанием для принятия уполномоченным органом решения об отказе во включении объекта нематериального этнокультурного достояния в Реестр является заключение экспертного совета о несоответствии указанного объекта критериям, установленным частью 1 статьи 8 настоящего Закона.

8. Граждане имеют право на беспрепятственное получение информации об объектах нематериального этнокультурного достояния в пределах сведений, содержащихся в Реестре.

## Статья 8. **Критерии отбора объектов нематериального этнокультурного достояния для включения в Реестр**

1. Объекты нематериального этнокультурного достояния для включения в Реестр должны соответствовать следующим критериям:

1) историческая и культурная значимость;

2) степень укоренения в культурной традиции или истории культуры этнической, социальной или конфессиональной группы;

3) ценность в качестве уникального свидетельства культурной традиции;

4) риск исчезновения.

2. Для включения в Реестр объект нематериального этнокультурного достояния должен соответствовать всем критериям, установленным частью 1 настоящей статьи.

Статья 9. **Выявление, изучение, использование, актуализация, сохранение, популяризация объектов нематериального этнокультурного достояния**

1. Уполномоченный орган обеспечивает и координирует деятельность по выявлению, изучению, использованию, актуализации, сохранению, популяризации объектов нематериального этнокультурного достояния.

2. Изучение объектов нематериального этнокультурного достояния осуществляется посредством организации научных, технических и искусствоведческих исследований, разработки научно-исследовательских методологий.

3. Актуализация и сохранение объектов нематериального этнокультурного достояния включают меры, направленные на обеспечение жизнеспособности объектов нематериального этнокультурного достояния, в том числе в их оригинальной форме.

4. Популяризация и использование объектов нематериального этнокультурного достояния обеспечиваются посредством проведения общественных мероприятий, в том числе по культурному обмену, а также путем создания условий для передачи элементов наследия их носителями молодому поколению и издания научных, научно-популярных и учебных работ.

5. Физические и юридические лица вправе оказывать содействие уполномоченному органу в выявлении, изучении, использовании, актуализации, сохранении, популяризации объектов нематериального этнокультурного достояния в соответствии с федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан.

Статья 10. **Государственная охрана объектов нематериального этнокультурного достояния**

1. Объекты нематериального этнокультурного достояния подлежат государственной охране в целях предотвращения их исчезновения, повреждения или разрушения материальных носителей, на которых они зафиксированы, а также в целях защиты таких объектов от иных негативных воздействий.

2. Государственная охрана объектов нематериального этнокультурного достояния включает в себя:

1) организацию научных исследований, работ, направленных на выявление объектов нематериального этнокультурного достояния, рассмотрение форм бытования и оценку их состояния, с подготовкой заключения экспертного совета;

2) формирование и ведение Реестра;

3) мониторинг и контроль за состоянием объектов нематериального этнокультурного достояния.

Статья 11. **Финансирование мероприятий по выявлению, изучению, использованию, актуализации, сохранению, популяризации и государственной охране объектов нематериального этнокультурного достояния**

Финансирование мероприятий по выявлению, изучению, использованию, актуализации, сохранению, популяризации и государственной охране объектов нематериального этнокультурного достояния осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан, а также иных источников, не запрещенных федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
06 апреля 2023 года
№ 30-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» 2017 елның 26 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**«Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын (алга таба – матди булмаган этномәдәни байлыклар) ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, аларны актуальләштерү, саклау, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә таяна һәм «Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни байлыклары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар,

Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

### 3 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары**

Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларына түбәндәгеләр керә:

1) халык авыз иҗаты, телдән-телгә тапшырыла торган традицияләр һәм аларны рус телендә, татар телендә, Россия Федерациясе халыклары телләрендә һәм диалектларында җиткерү рәвешләре;

2) традицион башкару осталыгы (нәфис сүз, җырлау, уен коралларында уйнау, бию) төрләре;

3) йолаларны, бәйрәмнәрне, гореф-гадәтләрне, уеннарны һәм халык мәдәниятенең башка төрләрен күрсәтү традицияләре;

4) яшәү рәвешенә һәм традицион кәсепләргә бәйле булган, билгеле бер территориядәге тарихи барлыкка килгән сюжетларда һәм образларда, аларны гәүдәләндерү стилистикасында гамәлгә ашырыла торган объектив рәвештә белдерелгән гыйлемнәр, аларны күрсәтү технологияләре, күнекмәләре һәм рәвешләре;

5) башка матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары.

### 4 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары категорияләре**

Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары түбәндәге категорияләргә бүленә:

1) Россия Федерациясе тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым тарихи, мәдәни һәм фәнни кыйммәткә ия булган федераль әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары;

2) Татарстан Республикасы тарихы һәм мәдәнияте өчен тарихи, мәдәни һәм фәнни кыйммәткә ия булган региональ әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары;

3) муниципаль берәмлекләр тарихы һәм мәдәнияте өчен тарихи, мәдәни һәм фәнни кыйммәткә ия булган җирле (муниципаль) әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары.

### 5 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мәдәният өлкәсендә матди булмаган этномәдәни байлыклар өлешендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә норматив хокукый актлар нәшер итү;

3) матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге чаралары булган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

4) региональ һәм җирле милли-мәдәни автономияләргә ярдәм итү;

5) халык сәнгать һөнәрләре оешмаларына (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган халык сәнгать һөнәрләре оешмаларыннан тыш) ярдәм күрсәтү;

6) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыклары мәдәниятенә ярдәм итүгә, аны саклауга, үстерүгә һәм өйрәнүгә, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының этномәдәни күптөрлелеген, шул исәптән матди булмаган этномәдәни байлыкларны, саклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

7) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләренә (алга таба – вәкаләтле орган) түбәндәгеләр керә:

1) матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, аларны актуальләштерү, саклау, популярлаштыру чараларын күрү;

2) мәдәният һәм сәнгать учреждениеләрен (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган федераль дәүләт мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән тыш) оештыру һәм аларга матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, аларны актуальләштерү, саклау, популярлаштыру өлешендә ярдәм күрсәтү;

3) Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары реестры (алга таба – Реестр) турындагы нигезләмәне раслау, аңа шул исәптән Реестрны формалаштыру һәм алып бару тәртибе, Реестрдан файдалану тәртибе, Реестрга матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын кертү хакында карар кабул итү тәртибе һәм Реестрдан матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын төшереп калдыру тәртибе, матди булмаган этномәдәни байлыклар объектына региональ яисә җирле (муниципаль) әһәмияттәге категория бирү тәртибе керә;

4) матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Реестрга яисә Россия Федерациясенең федераль дәүләт матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары реестрына кертү турында гаризалар кабул итү;

5) матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Федераль законда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенең федераль дәүләт матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары реестрына кертү хакында тәкъдим белән чыгу;

6) матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын дәүләт саклавын гамәлгә ашыру;

7) матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә региональ фәнни-техник һәм инновацион программаларны һәм проектларны, шул исәптән Татарстан Республикасы фәнни оешмалары тарафыннан да, оештыру һәм башкару;

8) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге фәнни һәм фәнни-техник программаларга һәм проектларга экспертизалар үткәрүне оештыру;

9) матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге чаралары булган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү;

10) эксперт советы төзү, эксперт советы турындагы нигезләмәне һәм эксперт советы составын раслау;

11) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендәге вәкаләтләрне Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыралар.

7 статья. **Реестр**

1. Татарстан Республикасында региональ һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын исәпкә алу, саклау, өйрәнү, актуальләштерү һәм популярлаштыру максатларында Реестр төзелә һәм алып барыла.

2. Реестр региональ һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары, аларны җиткерү ысуллары (рәвешләре), шулай ук аларга бәйле булган матди предметларны саклау урыннары турында мәгълүматның төп чыганагы булып тора.

3. Реестрдагы белешмәләр ачык, һәркем файдалана алырлык булалар һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

4. Вәкаләтле орган Реестрның операторы булып тора. Вәкаләтле органның карары нигезендә Реестрдан файдалану һәм аны үстерү вәкаләтләре аның ведомство буйсынуындагы учреждениегә тапшырылырга мөмкин.

5. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Реестрга кертү турында гариза матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын саклау һәм

популярлаштыру белән кызыксынган зат яисә гавами хакимият органы тарафыннан вәкаләтле органга бирелергә мөмкин. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Реестрга кертү йә матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Реестрга кертүдән баш тарту хакында карар гаризаны вәкаләтле органда теркәү көненнән алып бер елдан да соңга калмыйча кабул ителә.

6. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объекты Реестрга аның әлеге Законның 8 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән барлык критерийларга туры килүе һәм аңа региональ яисә җирле (муниципаль) әһәмияттәге категория бирү турында эксперт советының бәяләмәсе нигезендә вәкаләтле органның карары белән кертелә.

7. Күрсәтелгән объектның әлеге Законның 8 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән критерийларга туры килмәве турындагы эксперт советы бәяләмәсе матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Реестрга кертүдән баш тарту хакында вәкаләтле орган тарафыннан карар кабул итү өчен нигез булып тора.

8. Гражданнар Реестрдагы белешмәләр чикләрендә матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары турында мәгълүматны тоткарлыксыз алу хокукына ия була.

## 8 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын Реестрга кертү өчен сайлап алу критерийлары**

1. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары аларны Реестрга кертү өчен түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

1) тарихи һәм мәдәни әһәмиятлелеге;

2) этник, социаль яисә конфессиональ төркемнең мәдәни традициясендә яисә мәдәнияте тарихында ныклап урнашу дәрәҗәсе;

3) мәдәни традициянең уникаль дәлиле буларак кыйммәте;

4) юкка чыгу куркынычы.

2. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объекты аны Реестрга кертү өчен әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән барлык критерийларга җавап бирергә тиеш.

## 9 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, аларны актуальләштерү, саклау, популярлаштыру**

1. Вәкаләтле орган матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, аларны актуальләштерү, саклау, популярлаштыру эшчәнлеген тәэмин итә һәм җайга сала.

2. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын өйрәнү фәнни, техник һәм сәнгати тикшеренүләр оештыру, фәнни-тикшеренү методологияләре эшләү ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

3. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын актуальләштерү һәм саклау матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларының яшәү сәләтен тәэмин

итүгә, шул исәптән аларның оригиналь рәвешендә дә, юнәлдерелгән чараларны үз эченә ала.

4. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын популярлаштыру һәм алардан файдалану җәмәгать чаралары үткәрү, шул исәптән мәдәни алмашу буенча, шулай ук мирас элементларын аларның ияләреннән яшь буынга тапшыру өчен шартлар тудыру һәм фәнни, фәнни-популяр эшләрне һәм өйрәтү ярдәмлекләрен нәшер итү юлы белән тәэмин ителә.

5. Физик һәм юридик затлар вәкаләтле органга федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклауда, өйрәнүдә, алардан файдалануда, аларны актуальләштерүдә, саклауда, популярлаштыруда ярдәм күрсәтергә хокуклы.

10 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын дәүләт саклавы**

1. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары аларның югалуын, аларны теркәгән матди чыганакларның зарарлануын яисә ватылуын булдырмау, шулай ук мондый объектларны башка тискәре йогынтыдан саклау максатларында дәүләт тарафыннан сакланырга тиеш.

1. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын дәүләт саклавына түбәндәгеләр керә:

1) матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклауга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр, эшләр оештыру, аларның яшәү рәвешләрен карау һәм, эксперт советы бәяләмәсен әзерләп, аларның торышын бәяләү;

2) Реестрны формалаштыру һәм алып бару;

3) матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары торышын мониторинглау һәм тикшереп тору.

11 статья. **Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, аларны актуальләштерү, саклау, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын финанслау**

Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, аларны актуальләштерү, саклау, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка чыганаклардан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 30-ТРЗ